КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 ноябрь г.Казань № 974

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 922 нче карары белән расланган Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 922 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1317 нче, 2023 ел, 02 сентябрь, 1061 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 пунктның беренче абзацында «индикатор» сүзен «индикаторлар» сүзенә алмаштырырга;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 9 ноябрь, 974 нче
карары редакциясендә)

Узган ел белән чагыштырганда хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда файдаланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары

1. Узган календарь ел белән чагыштырганда, хуҗасыз хайваннарны урнаштыру эшчәнлеген гамәлгә ашыручы контрольдә тотучы зат тарафыннан (контрольдә тотылучы зат өчен) «Меркурий» федераль дәүләт мәгълүмат системасында рәсмиләштерелгән биологик калдыкларга ветеринария иярчен документлары нигезендә, шул ук зат тарафыннан шундый ук чор өчен урнаштырылган хайваннар санын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән мәгълүмат буенча 10 һәм аннан күбрәк процентка (әмма кимендә 3 берәмлеккә) арттыру факты булмаганда, биологик калдыклар санын 50 процентган күбрәккә арттыру.

2. Контрольдә тотылган затларда булган хайваннарда яки хайваннар өчен приютта салынган салынмый торган (юылмый торган) тамгалары булган хуҗаларсыз хайваннарда аеруча куркыныч авыру - котыру авыруы килеп чыгуның ике һәм аннан күбрәк очрагын ачыклау.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә бирелә торган хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда чаралар оештыру буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында документлар буенча хайваннар приютында булган хуҗаларсыз хайваннарның эвтаназия очракларының алдагы ел белән чагыштырганда бер ел эчендә 300 һәм аннан күбрәк процентка артуы (күрсәткечләр буенча).